Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы
# Мәктәп пульсы

№9
Май 2018 г.

## С днем великой Победы!




*Мы помним 45-й год,*
*Тогда страна вся ликовала,*
*«Конец войне!» — кричал народ.*
*Страна победу отмечала!*

*Сегодня слезы на глазах*
*У ветеранов... И не только...*
*Тоска и боль во всех сердцах,*
*Родных ведь потеряли столько!*

*Но этот праздник к нам пришел!*
*Победу всё же одержали!*
*И с этим праздником сейчас*
*Всех мы сердечно поздравляем!*

*Светлана Смирнова*



## Интересно знать!

- В Советском Союзе не отмечали праздник «День Победы» 17 лет.
- После войны в СССР осталось только 127 миллионов жителей.
- Получили звание Герой Советского Союза восемьдесят семь женщин.
- Медали выдавали только лишь после личного обращения граждан.
- Собаки обезвредили более четырех миллионов единиц фугасов и вражеских мин.
- Первый парад победы состоялся в Москве 24 июня 1945 года.

## Строй һәм җыр смотры

***4 нче май көнне мәктәптә “Строй һәм Җыр смотры” конкурсы узды. Ул Бөек Җиңүнең 73 еллыгына багышлап үткәрелде.***

Әлеге чара һәрбер балада ватанпәрвәрлек сыйфатлары тәрбияләү максатыннан оештырылды.

Рәт белән атлау һәм җырлап көч сынашу бик ансат булмады. Һәрбер сыйныф, алдан әзерләнеп, үзенчәлекле чыгыш күрсәтте. Бер төрдәге киемнәрдән булган, җыр башкару осталыгы, атлап йөрүләре белән игътибарны җәлеп итүчеләрнең чыгышлары жюри тарафыннан югары бәяләнде.

Әлеге матур һәм онытылмаслык бәйрәмне укытучылар гына түгел, якын-тирәдә яшәүчеләр, эти-әниләр дә күреп сокланды. Ә иң мөһиме: укучыларга ошады бу көн.

## В этом выпуске:


| | |
|---|---|
| Күпне күргән, күпне кичергән... | 2 |
| Чествование победителей и призеров олимпиад | 3 |
| Кыңгыраулы мәктәп елларын сагынып... | 4 |
| Кирилло-Мефодиевские чтения | 4 |
| Прощай, школа! | 5 |

# Күпне күргән, күпне кичергән...

***Сугыш... үзен күрмәсәң дә сагыш уята торган сүз бу. 73 ел вакыт үтсә дә, хатирәләре өлкәннәр күңелендә бик тирәнгә сеңеп калган. Ә авылдашым Хезмәт һәм тыл ветераны Сәрбиҗиһан Әсхәдуллина күңеленә алар мәңгелеккә кереп урнашкан диярсең.***

Сәрбия апай 1932 нче елның 27 нче августында Арча районы Түбән Мәтәскә авылында гап-гади колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. 1940 нчы елда мәктәпкә укырга керә. Тик балачакның якты мизгелләрен дәһшәтле сугыш еллары алыштыра. Шуңа да карамастан, укуын ташламый. Дүртьеллык авыл мәктәбен тәмамлагач, көн дә өч чакрымны җәяү йөреп, Күпербаш мәктәбендә тагын өч ел белем ала.

Алтынчы сыйныфта укыганда Сәрбия апаның әнисе үлә. Ике апасы да тормышка чыга, абыйсы колхозда эшли. Аңа җиде һәм тугыз яшьлек сеңелләрен карарга, өйдәге барлык эшләрне башкарырга туры килә.

Түбән Мәтәскәдән бер көндә 13 кешене сугышка алалар. Алар арасында Сәрбия апаның әтисе Әсхәдулла да була. Кызганычка каршы, аларның берсенә дә туган якларына кире кайту насыйп булмый. Ул хатларында авылына, туганнарына карата мәхәббәте хакында бүгенге көнгә кадәр Сәрбия апай күңелендә кадерле истәлек булып сакланган шигырьләр язгалаган, фотоларын җибәргәләгән. Шуларның берсе:

*Авылым Түбән Мәтәскә*
*Уртасыннан юл үтә.*
*Читтә йөргән якташларым,*
*Авылым сезне көтә.*

*Авылым Түбән Мәтәскә*
*Каршында биек таулар.*
*Тау итәгендә уйнашып*
*Җиләк җыя балалар.*

*Авылым Түбән Мәтәскә*
*Ия суы буенда.*
*Кайда гына яшәсәм дә,*
*Сез булырсыз уемда!*

Аталары сугыш кырында ятып калганлыктан, бер тапкыр субсидия бирәләр. Сеңелләре укуларын тәмамлагач, ул акча да бүтән бирелми. Нишләсен, гаилә ишле. Кыз олылыр белән берлектә урак урган, көлтә бәйләгән, ындыр табагында, фермада эшләгән.

18 яшь тулганнар өстендә урман кисү күрсәтмәсе тора иде. 1954 нче елның зәһәр февраль суыкларында, Лаеш урманында үзебездән ун тапкыр биек усак агачларын кисә башладык. Бу хәлләр әле дә күз алдымнан китми. Аякта чабата, бәйләгән оекбаш, өстебездә юка бишмәт... Планыбызны 12 көн эчендә үтәп, 30 чакрымны җәяү үтеп, Кызыл Байрак авылына килеп җиттек. Аннан безне машинада Казанга алып кайттылар. Бик авыр вакытлар булды, ләкин тешне кысып булса да, тормышны дәвам итәргә кирәк иде. Кияүгә чыктым. Ирем белән берлектә өч малай, бер кыз үстереп





аякка басырдык. Улларыбыз ике ел Кытай чигендә, Казанда, Әфганстанда армия сафларында хезмәт итеп, Ватан алдындагы бурычларын уңышлы үтәп кайттылар. Тормыш булгач, төрлесен күрәсең икән. Озакламый ирем, абыем фаҗигале төстә үлде, балалар хәсрәте буды. Тормышның сикәлтәле юлларыннан байтак үтелде. Ачлыкны да, ялангычлыкны да күрергә туры килде. Аллага шөкер, хәзер рәхәттә яшибез, - дип сөйләде ул.

Хезмәт һәм тыл ветераны Сәрбиҗиһан Әсхәдулла кызы Әсхәдуллина бүгенге көндә әтисенең төп нигезендә төпчек улы белән яши. Бәйрәм саен ул якташларына үзе язган искиткеч матур шигырьләрен бүләк итә. Шуңа күрә дә бар авыл кешесе аны ярата, хөрмәт итә.

Өченче меңьеллыкка аяк атлаганда киләчәктә сугышлар булмасын иде дигән теләк уяна. Батырларыбызның күп булуы белән горурланабыз без. Тик алдагы гасырларда яу кырында һәлак булганнар бөтенләй булмасын, ә безгә, моңа кадәр булган каһарманнарыбызны онытмыйча, аларны данлап һәм хөрмәтләп, тыныч тормышта яшәргә язсын иде!

**Рүзәл ШӘРИПОВ,**
8Б сыйныфы

# Чествование победителей и призеров предметных олимпиад



***16 мая в школе прошла торжественная церемония чествования победителей и призеров муниципального и республиканского этапов Всероссийской олимпиады школьников, а также ярких звездочек – активистов, кото-рые на протяжении двух и более лет являлись подмогой, опорой своих учителей, украшением различных школьных мероприятий.***

В 2017-2018 учебном году на муниципальном этапе Всероссийской олимпиады школьников от нашей школы приняло участие 141 ученик. Из них 59 учеников принесли школе призовые места, 1 ученица стала призером республиканского этапа Всероссийской предметной олимпиады.



- Как замечательно, что у нас есть ребята, чьи ум, знания и талант приносят нашей школе славу. Именно о вас можно сказать, что вы являетесь гордостью нашей школы, гордостью наших учителей и своих родителей! Ребята, вы – большие молодцы! Но олимпиадниками не становятся просто так. Это очень серьезный, системный труд всего педагогического коллектива, семьи и самого олимпиадника. И я хочу отдельно поблагодарить и поздравить наших учителей с таким успехом. Надеюсь, что в будущем учебном году количество призовых мест у нашей школы увеличится не только на муниципальном, а главное – на республиканском этапе олимпиады. Спасибо и вам, уважаемые родители, за ваше внушение детям важности, необходимости учиться, за вашу поддержку!

А вам, ребята, скажу: живите, дышите полной грудью, старайтесь, дерзайте! Будьте активными! Не останавливайтесь на достигнутом, двигайтесь вперед и развивайтесь! Все это сделает вас в будущем более успешными и конкурентоспособными! - сказала Гульназ Галиевна.



От имени педагогического коллектива школы выражается признательность и благодарность за финансовую помощь в проведении праздника нашему выпускнику, Сибагатову Назиму Хисамиевичу.

**Рузаль ШАРИПОВ,**
**8Б класс**

# Кыңгыраулы мәктәп елларын сагынып...

***Икенче мәктәпне 1973, 1978, 1983, 1988, 1993, 1998, 2003, 2008 һәм 2013 нче елда тәмамлаган укучыларның очрашу мизгелләреннән фоторепортаж***









# Кирилло-Мефодиевские чтения

***День славянской письменности и культуры широко отмечается ежегодно 24 мая в память о святых Кирилле и Мефодии, просветителях, создателях кириллической азбуки. Цикл мероприятий, посвященных данному событию, по традиции, 17 мая открывают XV Республиканские Кирилло-Мефодиевские юношеские научные чтения.***

17 мая в Казани в Гимназии № 93 прошел последний этап республиканской конференции. Более 250 школьников представили свои научно-исследовательские работы на заключительном этапе конференции. Среди них была и я – ученица 6Б класса Хайрутдинова Эльвина. Работа велась в 10 секциях по различным направлениям языкознания, литературоведения, декоративно-прикладного искусства. Тема моей работы - «Олицет-ворение как средство выразительности в сказке были М. М. Пришвина «Кладовая солнца. Моим руководителем была Хабреева Р.Б.

Мы побывали на экскурсии, где узнали о писателях и поэтах, посетивших Казань. Торжественное закрытие юбилейных чтений состоялось в концертном зале Дома Дружбы народов Татарстана.

Участники научных чтений были награждены дипломами I, II, III степени и памятными подарками. Я получила свидетельство об участии. Надеюсь, что обязательно поеду туда на следующий год.

**Эльвина ХАЙРУТДИНОВА,**
**6Б класс**

# Прощай, школа!



***Окончание школы – один из самых волнующих моментов нашей жизни. Позади беззаботное детство, шумные перемены, невыученные уроки. Начинается взрослая жизнь. Выпускной вечер – это праздник, который запо-минается на всю жизнь. Это один из самых красочных, теплых и массовых праздников.***

“Время меняется, и мы меняемся вместе с ним. Из маленьких и стеснительных первоклассников мы превратились в подростков, ясно осознающих смыл когда-то сказанных слов нашим любимым учителем…

Теперь мы понимаем: лучшее, что есть в нашей жизни на данный момент, - это школа, наша любимая школа, наш второй дом! Именно школьная жизнь наполняет мир красками.



Спасибо учителям, которые любят свою работу, нас, учеников, и отдают все знания и силы на развитие школы, её процветание, продвижение вперёд. Мы, выпускники 2018 года, покидая любимую школу, говорим всем: "Спасибо!". Желаем всем учителям и ученикам здоровья, исполнения желаний, удачи и новых побед!”

*От имени всех выпускников 2018 года*





**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.

***Дизайнер - верстальщик*** Рузаль Шарипов

***Фотокорреспондент*** Диана Галимова

***Корректор*** Данил Степанов

***Редколлегия*** Алия Хабирова

Гузель Насибуллина

***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15

***Сайт школы*** [https://edu.tatar.ru/arsk/sch2](https://edu.tatar.ru/arsk/sch2)